ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУСЛЮМОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29.08.2019 г. с. Муслюмово №___467_____

**Мөслим муниципаль районы һәм Мөслим авылы буенча 2001 елда туган һәм хәрби хезмәткә чакырылудан кичектерелү вакыты чыккан зурррак яшьтәге гражданнарга көзге чакырылыш үткәрү турында**

Мөслим һәм Мөслим муниципаль районы гражданнарын хәрби хезмәткә вакытында һәм оешкан төстә чакыру максатыннан, «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» 1998 елның 6 мартындагы 53 номерлы Федераль законның 22 ст., 23 ст., 24 ст., 25 ст., 26 ст., 27 ст., 28 ст., «Россия Федерациясе гражданнарын хәрби хезмәткә чакыру турында Нигезләмәне раслау хакында» 2006 елның 27 ноябрендәге 719 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә, Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Мөслим муниципаль районы һәм Мөслим авылы буенча хәрби хезмәткә чакырылу вакытына 18 яше тулган һәм хәрби хезмәткә чакырылудан кичектерү вакыты чыккан 1992-2000 елларда туган гражданнарны 2019 елның 1 октябреннән 31 декабренә кадәр көзге чакырылыш үткәрергә кирәк. Хәрби хезмәткә чакыру комиссиясе эшен 2019 елның 1 октябрендә 9.00 сәгатьтән башларга.

2. Мөслим үзәк район хастаханәсендә медицина тикшерүе үткәрергә. Сарман һәм Мөслим районнары хәрби комиссариатында гражданнарны хәрби хезмәткә чакыруны оештырырга һәм үткәрергә.

2.1 Хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле гражданнарның шикаятьләрен ачыклау өчен 2019 елның 16 сентябреннән башлап 8.00-13.00 сәгатьләрдә медицина тикшерүе оештырырга.

2.2. Медицина комиссиясе эшен түбәндәге срокларда оештырырга:

- хәрби хезмәткә чакырылучыларның медицина тикшерүе 2019 елның 1 октябреннән 08.00 башлап 31.12.2019 елга кадәр үткәрергә.

3.1. Хәрби хезмәткә чакырылучыларны сыйфатлы медицина тикшерүе һәм дәвалау өчен Мөслим үзәк район хастаханәсенең баш табибына:

- РФ Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылучыларның анализларны чиратсыз тапшыруны, күкрәк читлеген, йөрәк ЭКГсын төшерүне тәэмин итәргә;

- хәрби хезмәткә яраклылыгын билгеләү максатыннан стационар тикшерү өчен, район үзәк хастаханәсенең һәр бүлегендә 1-2 койка - урын бүлеп бирергә;

- Сарман һәм Мөслим районнары хәрби комиссариатына амбулатор авыруның медицина карталарын (25нче форма) һәм яшүсмер өстәмә битләрен (25нче форма) тапшырырга;

- медицина тикшерүе үткәрү өчен хәрби хезмәткә чакырылучыларны квалификацияле табиб-белгечләргә бүлеп бирергә:

**Төп состав:**

- Өлкән врач - И.А. Шамсутдинов
- терапевт - И.А.Шамсутдинов
- отоларинголог - Р.И. Мустаев
- хирург - Р.Ф. Ханов
- стоматолог - А.Н. Сафина
- невролог - Д.А. Гайфиева
- психиатр - Т.Н. Бишимов
- офтальмолог - Н.Г. Гайнетдинова
- дерматолог - И.М. Латыпов

**Резерв составы:**

- Өлкән врач - Л.А.Мингазова
- терапевт - Л.А.Мингазова
- отоларинголог - Д.Ю. Зиганшин (Сарман РҮХ)
- хирург - З.Ф. Фатхутдинов
- стоматолог - С.М. Ахметханов
- невропатолог - Р.Х. Тенешев (Сарман РҮХ)
- психиатр - З.М. Измаилова (Сарман РҮХ)
- окулист - Н.М. Точилкина (Сарман РҮХ)
- дерматолог - Ш.Г. Абдуллин (Сарман РҮХ)

һәм 16.09 еннән 2019 елның 31 декабренә кадәр 8 кешелек урта медицина персоналы.

3.2. Хәрби хезмәткә чакыру пунктында эшләү чорында комиссия әгъзаларын, табибларны һәм урта медицина персоналын төп эштән, алар артында биләгән вазыйфаларын һәм уртача айлык хезмәт хакын саклап калудан азат итәргә, алга таба Татарстан Республикасы хәрби комиссариатыннан түләргә.

3.3. - Россия Эчке эшләр министрлыгының Мөслим районы буенча бүлеге начальнигына хәрби хезмәткә чакыру медицина комиссиясен уздыру чорына чакыру пунктында тәртип тәэмин итү өчен бер милиция хезмәткәрен бүлеп бирергә;

- хәрби хезмәткә чакырылудан качып йөрүчеләрне эзләү буенча оператив чаралар үткәрү өчен эзләү төркемен төзергә (уртак боерык нигезендә);

- Сарман һәм Мөслим районнары хәрби комиссариаты гаризасы буенча, хәрби хезмәткә чакырылучыларны Татарстан Республикасының җыелма пунктына озаткан көннәрдә график нигезендә

озатучылар арасында җәмәгать тәртибен саклау өчен, полиция нарядын бүлеп бирергә кирәк.

3.4. Барлык милек формасындагы предприятие, оешма, учреждение, уку йортлары җитәкчеләренә, җирлек башлыкларына:

- Сарман һәм Мөслим районнары хәрби комиссариатына чакыру турында хәбәр итәргә;

- хәрби хезмәткә чакыру комиссиясенә һәм хәрби хезмәткә озатканда чакырылучыларны үз вакытында һәм оешкан төстә чакыруны тәэмин итәргә;

- армиягә чакырылучыларны, чакыру комиссиясенә илтү өчен кешеләр йөртү өчен җиһазландырылган транспорт белән тәэмин итәргә;

- хәрби хезмәткә чакырылучыларны тантаналы озату оештырырга;

- хәрби хезмәт үтү өчен җибәрелгән чакырылучыларны чакыру кәгазе буенча акчалата исәп-хисап ясарга;

- Татарстан Республикасы Хәрби комиссариатының Сарман һәм Мөслим районнары буенча бүлегенә хәрби хезмәткә чакырылучыларны исерек хәлдә озату очракларына юл куймаска.

3.5. Сарман һәм Мөслим районнары хәрби комиссарына, һөнәри-психологик сайлап алу комиссиясенә хәрби хезмәткә чакырылучыларны хәрби белгечлекләр төркемнәре буенча рациональ бүлү һәм хәрби-һөнәри ориентацияне ачыклау максатыннан профессиональ-психологик сайлап алуны үткәрергә.

4. Мөслим муниципаль районы мәгариф бүлеге җитәкчесенә, суицидаль билгеләрне башлангыч стадиядә ачыклау, хәрби хезмәтнең яңа шартларына тиз арада җайлашу өчен, РФ Коралллы Көчләренә чакырылырга тиешле хәрби хезмәткә чакырылучыларга психологик ярдәм күрсәтү өчен, психолог җибәрергә.

5. Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге җитәкчесенә 2019 елның 24 октябрендә гаскәрләргә озатылырга тиешле гражданнарның ата-аналарын җәлеп итеп район күләмендә «Призывник көне» үткәрергә.

**Башкарма комитет җитәкчесе**
**вазыйфаларын башкаручы** **И. Х. Әхмәтов**